КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 апрель г.Казань № 281

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждение-ләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1041 нче, 2019 ел, 26 ноябрь, 1080 нче, 2020 ел, 03 февраль, 69 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр, 2020 елның 1

гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш.»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 13 – 19 пунктчалар өстәргә:

«13) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган милекне саклау өлкәсендә административ хокук бозулар өчен (вак урлаулар өчен штрафлар) административ штрафлар;

14) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган милекне саклау өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

15) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (ау кагыйдәләрен, балыкчылыкны һәм хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны регламентлый торган кагыйдәләрне бозган өчен штрафлар);

16) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

17) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 18 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган Россия Федерациясе дәүләт чиген яклау һәм Россия Федерациясе территориясендә чит ил гражданнарының яисә гражданлыгы булмаган затларның булу режимын тәэмин итү өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар;

18) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган идарә итү тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

19) 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16) «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган

эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм үз-үзен көйләүче оешмалар эшчәнлеге өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар).»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, аның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенә беркетелгән керемнәр чыганаклары:

1) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган элемтә һәм мәгълүмат өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

2) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм үз-үзен көйләүче оешмалар эшчәнлеге өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция сату кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

3) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм үз-үзен көйләүче оешмалар эшчәнлеге өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (физик затлар тарафыннан алкогольле һәм спиртлы азык-төлек продукциясен законсыз саткан өчен штрафлар);

4) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм үз-үзен көйләүче оешмалар эшчәнлеге өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

5) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган финанс, салымнар һәм җыемнар, иминиятләштерү, кыйммәтле кәгазьләр базары өлкәсендә административ хокук бозулар өчен (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш) административ штрафлар (мәгълүматны маркировкалау һәм (яки) төшерү, тиешле маркировкасыз һәм (яки) мәгълүматсыз, шулай ук мондый маркировкалау һәм (яки) мәгълүмат китерүнең билгеләнгән тәртибен бозып, товарлар һәм продукцияне җитештерү яки саткан өчен штрафлар);

6) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган финанс, салымнар һәм җыемнар, иминият, кыйммәтле кәгазьләр базары өлкәсендә административ хокук бозулар өчен (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46

статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән штрафлардан тыш) административ штрафлар (башка штрафлар);

7) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган дәүләт хакимияте институтларына кул суза торган административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (административ хокук бозу турындагы эш буенча эш алып баручы прокурор, тикшерүче, сорау алучы яисә вазыйфаи затның законлы таләпләрен үтәмәгән өчен штрафлар);

8) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган дәүләт хакимияте институтларына кул суза торган административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

9) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган идарә итү тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (дәүләт күзәтчелеген (контролен) гамәлгә ашыручы орган (вазыйфаи зат), федераль законнар нигезендә дәүләт (вазыйфаи зат) күзәтчелеген, муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган (вазыйфаи зат) тарафыннан законлы күрсәтмәне (карарларны, күрсәтмәләрне, карарларны) вакытында үтәмәгән өчен штрафлар;

10) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган идарә итү тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (белешмәләр (мәгълүмат) бирмәгән өчен штрафлар);

11) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган идарә итү тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының вазыйфаи затының, оешманың федераль законнар нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затының, муниципаль контроль органының вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулаган өчен штрафлар);

12) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган идарә итү тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

13) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20 бүлегендә билгеләнгән җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган җәмәгать

тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын бозучы административ хокук бозулар өчен административ штрафлар (башка штрафлар);

14) 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр;

15) 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр (муниципаль юл фондын формалаштыруга җибәрелә торган керемнәрдән, шулай ук муниципаль берәмлекнең финанс органы тарафыннан бурычларны аерым исәпкә алу турында карар кабул ителгән очракта бүтән түләүләрдән тыш, шәһәр округлары бюджетларының керемнәре);

16) 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2019 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр (муниципаль юл фондын формалаштыруга җибәрелә торган керемнәрдән, шулай ук муниципаль берәмлекнең финанс органы тарафыннан бурычларны аерым исәпкә алу турында карар кабул ителгән очракта бүтән түләүләрдән тыш, шәһәр округлары бюджетларының керемнәре).»;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә беркетелгән керемнәр чыганаклары:

2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин